| ГЛАВА<br>ЭБАЛАКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29февраль,2024 Ябалак авылы № 2

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Морза Бәрлебаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 нче карарына үзгәреш кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Морза Бәрлебаш авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыены әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 30 сентябрендәге 110 номерлы карары нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2024 елның 18 мартында 11 сәг 00 минутта Морза Бәрлебаш авылы,Беренче Май урамы,32Б йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Морза Бәрлебаш торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 нче карарына үзгәреш кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«Сез«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Морза Бәрлебаш торак пунктындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 нче карарына җирле

әһәмияттәге сорауларны хәл итү буенча эшләр исемлеге өлешендә үзгәртергә һәм 2024 елда алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә ризамы:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен урнаштыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау ( шул исәптән светодиодлы урам яктырткычлары, таймер, СИП чыбыклары сатып алу);
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (шул исәптән янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән территорияне, балалар мәйданчыгы тирәсен чабу).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Ябалак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгару юлы белән халыкка таратырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавалылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф.